имзалаган һәм әлеге Нигезләмәнең 4.1 пунктында каралган анкета-гаризада күрсәтелгән адреска җибәрелгән заказлы рәсми хат белән хәбәр ителә.

4.12. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (почта, командировка һ.б.) Гариза бирүче/Катнашучы тарафыннан мөстәкыйль түләнә.

## 5. Конкурс эшләрен бәяләү

5.1. Конкурс эшләрен бәяләү критерийлары:

конкурс материалларының Конкурс максатларына һәм бурычларына туры килүе (0-5 балл);

тәкъдим ителгән материалларның тәрбияви һәм иҗтимагый кыйммәте, авторның гражданлык позициясе чагылу (0-5 балл);

тәкъдим ителгән материалларның актуаль һәм дөрес булуы, анализ тирәнлеге (0-5 балл);

материалларның югары һөнәри дәрәҗәдә эшләнгән булуы (максатчан төркемнәр тарафыннан җиңел кабул ителүе, сәнгати алымнар куллану, югары сыйфатлы дизайн һәм бизәлеш, композицион-структура төзелеш) (0-5 балл);

концепциянең, сценарийның, теманың, теманы яктыртуның тапталмаган булуы һәм индивидуаль иҗат стиле булу (0-5 балл).

5.2. Баллар суммасы призлы урыннар буенча түбәндәгечә бүленә:

1 урын: 21 – 25 балл

2 урын: 16 – 20 балл

3 урын: 11 – 15 балл

## 6. Конкурс комиссиясен оештыру һәм аның эшчәнлек тәртибе

6.1. Конкурс комиссиясенең составы Конкурсны оештыручы тарафыннан раслана, 6 әгъзадан тора, аларга рәис, рәис урынбасары һәм әгъзалар керә.

6.2. Конкурс комиссиясе үз эшен түләүсез башкара.

6.3. Конкурс комиссиясенең эше утырышларда гамәлгә ашырыла. Утырышта комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, утырыш тулы хокуклы дип танылa.

6.4. Конкурс эшенә рәис җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, рәис вазыйфалары аның тарафыннан билгеләнгән урынбасарына йөкләнә.

6.5. Конкурс комиссиясе әгъзалары конкурска тапшырылган эшләрне әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән Конкурс эшләрен бәяләү критерийлар нигезендә бәяли. Һәрбер критерий буенча балларның саны 5 баллы шкала (0 – 5 балл) буенча бәяләнә.

6.6. Конкурска бер генә гариза тапшырылса, бер гариза да тапшырылмаса, тапшырылган гаризаларның берсе дә конкурс шартларына туры килмәсә, катнашкан эшләрнең берсе дә билгеләп үтәргә лаек дип танылмаса, Конкурс үткәрелмәгән дип танылa һәм акчалар Оештыручы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарыла.

6.7. Һәрбер критерий буенча баллар суммасыннан чыгып, конкурс комиссиясе конкурста катнашучыларның рейтингын төзи. Рейтингта 1 – 3 урыннарны алган

